**МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ ДОШКОЛЬНОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ**
**«ДЕТСКИЙ САД № 63 КОМБИНИРОВАННОГО ВИДА»**
420108, г.Казань, ул.Мазита Гафури, д.2а т.293-37-49

| | |
|---|---|
| Мотивированное мнение Совета родителей (законных представителей) воспитанников МБДОУ «Детский сад № 63» учтено | «Утверждаю»<br>Заведующая МБДОУ «Детский сад № 63»<br>__________________ М.Ю.Безделева<br>(подпись) (фамилия, инициалы) |
| ПРИНЯТ<br>Педагогическим советом МБДОУ «Детский сад № 63 комбинированного вида»<br>протокол № 1 от 31 августа 2022г. | Введен в действие приказом по МБДОУ «Детский сад № 63 комбинированного вида» Вахитовского района г.Казани<br>от « 31 » августа 2022 г. №__52-П___ |

# Рабочая программа
## воспитателя по обучению татарскому языку в средней, старшей и подготовительной группе комбинированного вида
## муниципального бюджетного дошкольного образовательного учреждения «Детский сад № 63 комбинированного вида» Вахитовского района г. Казани
# МИНГАЛИЕВОЙ Н.Б.
# на 2022-23 учебный год

**2022 г.**

**ЭЧТӘЛЕК**

I.Аңлатма язуы........................................................................................................3-4
2.Норматив документлар исемлеге.......................................................................4-5
3.Характеристика особенностей развития детей дошкольного возраста..................5-
3.1Возрастные психологические особенности дошкольников 4 - 5 лет
с нарушением интеллекта…………………………………………………………..5
3.2 Возрастные психологические особенности дошкольников 5 – 6 лет с нарушением интеллекта……………………………………………………………………………5
3.3 Возрастные психологические особенности дошкольников 6 – 7 лет с нарушением интеллекта……………………………………………………………………………5-6
3.4 Индивидуальные особенности контингента детей с задержкой психического развития………………………………………………………………………….......6
3.5 Возрастные психологические особенности дошкольников 5 - 6 лет с задержкой психического развития……………………………………………………………………………6
3.6 Возрастные психологические особенности дошкольников 6 – 7 лет с задержкой психического развития……………………………………………………………………………6
3.7 4 – 5 яшьлек балаларның яшь үзенчәлекләре...................................................7
3.8 5 яшьтән алып 6 яшькәчә балаларның яшь үзенчәлекләре................................7
3.9 6 -7 яшьлек балаларның психик үсешенең яшь үзенчәлекләре..........................7-8
4. Балалар бакчасында тәрбияләнүче балаларның индивидуаль һәм яшь үзенчәлекләре....8
5. Программа принциплары.......................................................................................8-9
6.Татар телен өйрәтүдә кулланыла торган чаралар.................................................9
7.Эш төрләре һәм формалары...................................................................................9
8.Укыту методик комплектының эчтәлеге.................................................................9
9.Татар теле өйрәтү программасы............................................................................9-10
10.Показатели развития -Үсеш күрсәткечләре.........................................................10
11.Целевые ориентиры, сформулированные в ФГОС дошкольного образования по обучению татарскому языку...........................................................................................................10-11
12.Балаларга татар теле өйрәтү программасы..........................................................12-11
12.1 «Минем өем» проекты (4–5 яшь)...........................................................11-12
12.2 “Уйный – уйный үсәбез” проекты. (5-6 яшьлек балалар өчен)...........................12
12.3 «Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар» проекты (6–7 яшь)....................12-13
12.4 Акыл үсешләрендә тоткарлык булган балаларга татар телен өйрәтү буенча бердәм белем бирү челтәре......................................................................................................13-14
12.5 Белем бирү эшчәнлеген планлаштыру..........................................................14
12.5.1 Беренче уку елы, уртанчылар төркеме........................................................14
12.5.2 Икенче уку елы, зурлар төркеме.............................................................14-15
12.5.3 Өченче уку елы, мәктәпкә хәзерлек төркеме..........................................16-17
13. Төркемнәрдә коррекцион эш......................................................................17-19
14.Методик киңәшләр......................................................................................19-36
14.1 Сүзлек белән эшләү.......................................................................................19
14.2Аралашуга чыгу чаралары- аудиоязмалар, эш дәфтәрләре, анимацион сюжетлар....19-21
14.3 Тематик планнар.......................................................................................21-27
14.4 Татар телендә сөйләшә (аралаша) белү күнекмәләрен тикшерү...............................27-36
15. Кушымта.......................................................................................................36-40
15.1Күрсәтмә, таратма материаллар..........................................................37-40
15.2 Анимацион күренешләр.....................................................................40-41
15.3 Методик әсбаплар..........................................................................................41-42
15.4 Материаль-техник тәэмин итү.........................................................................42
Файдаланылган әдәбият........................................................................................42-43

# 1.АҢЛАТМА ЯЗУЫ

“Татарстан Республикасы халыклары телләре турында” Татарстан Республикасы Законында һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә кабул ителгән 2010 – 2015 елларда мәгарифне үстерү стратегиясендә (30.12.2010, №1174) – мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре өчен рус һәм башка милләт балаларын татарча сөйләшергә өйрәтү программасы, укыту-методик комплектлары (УМК) төзү бурычы куелды.

Программа интеллектуаль үсешләрендә тоткарлык булган 4 яшьтән 7 яшькә кадәр рус телле балаларның татарча аралашырга өйрәтү эшчәнлекләрен үз эченә ала. Программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш закончалыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фундаменталь тикшеренүләргә, тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына, сөйләм барлыкка килү концепциясенә (О.А.Куревина-Л.Г.Петерсон,Л. С. Выготский, В. В. Давыдов, Е. И. Пассов, П. Я. Гальперин), гамәли эшкәртмәләр һәм методик киңәшләргә, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив хокукый актлар, нигезләмәләренә көйләнгән.

Җайлаштырылган программа 4-5-6 яшьлек балаларның психофизиологик үзенчәлекләрен күздә тотып,компенсацияләүче төркемдә тәрбияләнүче балалар өчен эшләнде.

Дети с ОВЗ- ограниченными возможностями здоровья – это дети, состояние здоровья которых препятствует освоению образовательных программ вне организации специальных условий обучения и воспитания. Самым главным приоритетом в работе с такими детьми является индивидуальный подход с учетом специфики нарушения и особенностей здоровья каждого ребенка. Но в условиях инклюзивного образования дети с ОВЗ и дети с нормой развития находятся в равных условиях, должны получать равное воспитание и обучение, но все же специфика работы с определенным нарушением у ребенка с ОВЗ должна быть.

Адаптированная программа рассматривает:

- в качестве объекта развития – психофизиологический,мотивационно-ценностный,интеллектуальный,социально – личностный и эмоционально – волевой готовности дошкольника с особенностями психосоциального развития к школьному обучению;
- в качестве движущих сил – актуализацию внутреннего потенциала дошкольника с особенностями психосоциального развития и укрепление его физического здоровья;
- в качестве психологического механизма – саморазвитие ребенка,осуществляемое как посредством актуализации индивидуальных психофизиологических ресурсов,так и в процессе специально организованной коррекционно-развивающей работы;
- в качестве результата развития – полноценное развитие личности дошкольника и формирование его интегративной готовности к школьному обучению.

Особенностью данной адаптированной программы является ее эффективное использование на этапе предшкольного образования следующих категорий детей:

- с нарушениями речевого развития;
- с ОВЗ.

Наша задача – создать в мозгу ребенка образ основных структур языка.Поскольку в данном возрасте речевые механизмы еще не полностью сформировались и действует механизм импринтинга,наиболее эффективным представляется естественный путь создания образа языка у ребенка-через многократное прослушивание отрабатываемых структур(в том числе аудиокомплекс).Программа ориентируется на непроизвольность памяти и внимания,способность к импритингу и на игру как на основной вид деятельности.

## 2.Норматив документлар исемлеге

- Федеральный закон от 29.12.2012 N 273-ФЗ (ред. от 23.07.2013) «Об образовании в Российской Федерации»,
- Приказ Минобрнауки России от 30.08.2013 N 1014 «Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам - образовательным программам дошкольного образования»,
- ФЗ от 24.07.1998 № 124 – ФЗ (редакция от 25.11.2013 г.) «Об основных гарантиях ребенка в Российской Федерации»,
- Приказ Минобрнауки РФ от 17.10.2013 «Об утверждении федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования»,
  - СП 2.4.3648-20 «Санитарно-эпидемиологические требования к организациям воспитания и обучения, отдыха и оздоровления детей и молодежи», утвержденными постановлением главного санитарного врача от 28.09.2020 № 28;
- СанПиН 1.2.3685-21 «Гигиенические нормативы и требования к обеспечению безопасности и (или) безвредности для человека факторов среды обитания», утвержденными постановлением главного санитарного врача от 28.01.2021 № 2Приказ Министерства труда и социальной защиты РФ от 18.10.2013 №544 «Об утверждении профессиональных стандартов педагога»;
- Устав ДОУ
- Образовательная программа МБДОУ
- ФГОС дошкольного образования (утверждено Советом Минобрнауки′ РФ 28.08.2013 г.).
- Профессиональный стандарт педагога (педагогическая деятельность в′ сфере дошкольного, начального общего, основного общего, среднего общего образования). (Приказ Министерства труда и социальной защиты РФ от 18.10.2013. №544н).
- Положение о кабинете татарского языка.
- Закон Республики Татарстан «О языках народов Республики Татарстан». Приказ от 29.06.2001г. № 463 «О мерах по улучшению изучения родного, татарского, русского языков в ДОУ».
- Закон РТ от 12.01.2013г. №1-ЗРТ «Об использовании татарского языка как государственного языка Республики Татарстан».
- Письмо от 29 января 2013 г. № 968/13 «Об эффективном внедрении новых УМК».
- “Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү: программа, методик киңәшләр, диагностика»/ «Обучение русскоязычных детей татарскому языку в детском саду», авт. З.М. Зарипова, Р.Г. Кидрячева, Р.С. Исаева и др.
- Учебно-методический комплект «Говорим по-татарски» («Татарча сөйләшәбез»), по обучению русскоязычных детей 4-7 лет татарскому языку, авторы Зарипова З.М., Исаева Р.С., Кидрячева Р.Г.
- Региональная образовательная программа дошкольного образования «Сөенеч» – «Радость познания», авт. Р.К. Шаехова.
- Методическое пособие по обучению родному татарскому языку детей 1 мл. гр. авт. Хазратова Ф.В. 22.11.2012 г
- Программа предшкольного образования детей с особенностями психосоциального развития «Я другой»,авт.Л.Ф.Блинова,Ю.Л.Блинова,Н.М.Петрова.Казань:Магариф,2009г
- -УМК «Говорим по-татарски» - «Татарча сөйләшәбез» по обучению русскоязычных детей 4-7 лет татарскому языку (Зарипова З. М., Кидрячева Р. Г.).

## 3. Характеристика особенностей развития детей с ОВЗ дошкольного возраста.

Возрастные характеристики особенностей развития детей дошкольного возраста сформулированы в «Дошкольной педагогике с основами методик воспитания и обучения» : Дошкольная педагогика с основами методик воспитания и обучения: учебник для вузов. Стандарт третьего поколения (под.ред. А.Г.Гогоберидзе,О.В.Солнцевой .СПб.Питер,2013.-464 с)

**Возрастные особенности детей в группах компенсирующей направленности** сформулированы по программе дошкольных образовательных учреждений компенсирующего вида для детей с нарушением интеллекта «Коррекционно-развивающее обучение и воспитание» под редакцией Е.А. Стребелевой, Е.А. Екжановой (2010г.)

У детей с нарушением интеллекта особая форма психического недоразвития, возникающая вследствие различных причин: патологической наследственности, хромосомных аберраций, при родовой патологии, органического поражения центральной нервной системы во внутриутробном периоде или на самых ранних этапах постнатального развития. Органическое поражение ЦНС носит не прогрессирующий характер. Дети способны к развитию, которое подчинено общим закономерностям формирования психики, но имеет свои особенности, обусловленные типом нарушений ЦНС и их отдаленными последствиями.

### 3.1Возрастные психологические особенности дошкольников 4 - 5 лет с нарушением интеллекта.

· Детям присуще наглядно - действенное мышление.

· Интеллектуальное развитие зависит от того, насколько богата окружающая среда, т. е. позволяет ли она разнообразно и содержательно исследовать окружающий мир, манипулируя различными предметами.

· Речь находится в стадии формирования.

· Обучение эффективно только на фоне психоэмоционально - комфортного состояния.

· Внимание, мышление, память - непроизвольно.

### 3.2 Возрастные психологические особенности дошкольников 5 – 6 лет с нарушением интеллекта.

· Мышление носит наглядно-образный характер;

· Внимание, память, мышление остаются непроизвольными;

· Речь находится в стадии формирования;

· Ребенок познает мир, непосредственно окружающий его в данный момент.

· Сохраняется непроизвольный характер основных психических процессов: внимания, мышления, а также эмоциональная лабильность и потребность в эмоциональном комфорте.

· Ведущим типом общения становится ситуативно - деловое

### 3.3Возрастные психологические особенности дошкольников 6-7 лет с нарушением интеллекта.

· Мышление носит наглядно-образный характер.

· Дети проявляют интерес к волшебным сказкам и легче воспринимают информацию, если она касается кого-то живого.

· Ребенок может произвольно управлять своим поведением, а также процессами внимания и запоминания, эмоциональными реакциями.

· В любом виде деятельности может выйти за пределы сиюминутной ситуации, осознать временную перспективу, удерживать в сознании одновременно цепочку взаимосвязанных событий или разные состояния вещества или процесса.

· Ведущее значение приобретает развитие воображения.

### 3.4 Индивидуальные особенности контингента детей с задержкой психического развития

У детей данной категории все основные психические новообразования возраста формируются с запаздыванием и имеют качественное своеобразие. Для них характерна значительная неоднородность нарушенных и сохранных звеньев психической деятельности, а так же ярко выраженная неравномерность формирования разных сторон психической деятельности. Такие дети не имеют нарушений отдельных анализаторов и крупных поражений мозговых структур, но отличаются незрелостью сложных форм поведения, целенаправленной деятельности на фоне быстрой истощаемости, утомляемости, нарушенной работоспособности, в основе ЗПР – органическое заболевание ЦНС.

### 3.5 Возрастные психологические особенности дошкольников 5 - 6 лет с задержкой психического развития.

-низкий уровень развития восприятия (по сравнению с нормально развивающимися сверстниками);
-отклонения в развитии внимания: неустойчивость, рассеянность, низкая концентрация, трудности переключения;
-неравномерная работоспособность;
-отклонения в развитии памяти: заметное преобладание наглядной памяти над словесной, большая сохранность непроизвольной памяти по сравнению с произвольной, недостаточный объём и точность запоминания;
-выраженное отставание и своеобразие обнаруживается и в развитии познавательной деятельности: дети не владеют представлениями об основных цветах, геометрических формах, времени и пространстве.
-нарушен поэтапный контроль над выполняемой деятельностью: они часто не замечают несоответствия своей работы предложенному образцу, не всегда находят допущенные ошибки, даже после просьбы взрослого проверить выполненную работу.
снижена потребность в общении как со сверстниками, так и со взрослыми.
-нарушения речи: одни используют довербальные средства общения, другие пользуются простой фразой, аграмматичной, структурно нарушенной;

### 3.6 Возрастные психологические особенности дошкольников 6 – 7 лет с задержкой психического развития.

-ослаблено здоровье и отмечается сниженный уровень физического и психофизического развития;
-не сформирована мотивационная готовность. Даже если ребенок хочет идти в школу, в большей степени его привлекает учебная атрибутика - в школе он будет играть, а не учиться;
-отмечается низкий уровень эмоционально-волевой готовности. Ребенок не может подчинится правилам дисциплины, неспособен к длительным интеллектуальным усилиям;
-не сформированы все структурные компоненты учебной деятельности;
-испытывают трудности при выполнении заданий, связанных на развитие мелкой моторики;
-непроизвольное внимание развито значительно лучше, чем произвольное;
-несоответствие между уровнем наглядно действенных операций и словесно-логического мышления;
-могут быть нарушены эмоциональные контакты с близкими взрослыми, дети слабо ориентируются в нравственно-этических нормах поведения.

### 3.7 4-5 яшьлек балаларның яшь үзенчәлекләре.

Уртанчы мәктәпкәчә яшьтәге интеллектуаль үсешләрендә тоткарлык күзәтелгән балаларның уен эшчәнлегендә рольле мөнәсәбәтләр барлыкка килә. Бу яшьтәге балалар кабул ителгәндә рольдән үзләрен аера башлыйлар. Уен процессында рольләр үзгәрергә мөмкин Кечкенәләр белән чагыштырганда балалар бу яшьтә тигезлекне яхшы саклыйлар, зур булмаган тоткарлыкларны атлап чыгаралар. Туп белән күнегүләр катлаулана. Зиһенгә алу сәләте күбрәк үсеш ала. Балалар предмет төркемнәрен сенсорик билгеләре – зурлыгы, төсе буенча тәртипкә салырга, биеклек, озынлык һәм киңлек кебек параметрларны аерырга өйрәнә башлый. Хәтер күләме үсә. Балалар 7-8 предметның исемен истә калдыра алалар. Истә калдыру мөмкинлекләре үсә. Алар олылар тапшырган эшне үти башлыйлар. Бала 15-20 минут дәвамында игътибарын туплап эшли алырга сәләтле була башлый. Ул нинди дә булса эш эшләгәндә катлаулы булмаган шартны хәтерендә тотып тора ала. Авазлар әйтелеше яхшыру күзәтелә. Сөйләм балаларның активлыгын үстерә. Алар хайван тавышлары чыгаралар. Теге яки бу персонажның сөйләмен интонация белән аерып күрсәтә алалар. Бер-берсе белән аралашканда балаларның сөйләме ситуациягә бәйле, ә олылар белән аралашканда ситуациягә бәйләнмәгән була. Бала белән олыларның аралашу эчтәлеге үзгәрә. Ул бала элләккән конкрет ситуациядән читкә тайпыла. Танып белү мотивы алга чыга. Аралашу процессында алган мәгълүматлар бик үк аңлашылып бетмәсәләр дә, балада кызыксыну уяталар. Уен вакытында даими партнерлар барлыкка килә. Төркемдә лидерлар аерылып чыга башлый. Көндәшлек, ярышу барлыкка килә. Ярышу үзеңне башкалар белән чагыштыру өчен әһәмиятле. Бу үз чиратында “Мин” образының үсешенә, аның детальләштерүенә китерә. Бу яшьнең төп казанышлары уен эшчәнлеге үсү; зиһенгә алу сәләте камилләшү, танып белүдә мин-минлек (минеке генә дөрес дигән позиция); хәтер, игътибар, сөйләм, дәлилли белү сәләте үсү, олыларның хөрмәтенә ихтыяҗ формалашу, үпкәләүчәнлек, көндәшлек, ярышу кебек сыйфатлар барлыкка килү белән характерлана.

**3.8 5 яшьтән алып 6 яшькәчә балаларның яшь үзенчәлекләре.** Бу яшьтәге балалар уен башыннан рольләрне тәрбияче ярдәмендә бүлеп, шушы рольгә кереп уйный башлыйлар. Уен барышында үзара мөнәсәбәт эчтәлеге буенча да, интонациясе буенча да рольгә туры килгән аралашу белән үрелеп бара. Балаларның чынлыкта аралашкан сөйләм теле, роль сөйләм теленнән аерылып тора. Балалар социаль мөнәсәбәтләрне аңлый башлыйлар, кайсыдыр роль башкалар белән чагыштырганда алар өчен якынрак була. Рольләр бүлгәндә төрле конфликтлар чыгарга мөмкин. Уен тирәлеге оешканлыгы күзәтелә, “үзәк” һәм “периферия” аерылып чыга. (“Больница” уенында үзәк – врач кабинеты, “Парихмахерская” уенында – чәч кисү залы – үзәк, көтү залы – периферия). Уеннарда балаларның эш гамәлләре күпкырлыга әйләнә. Сөйләм үсеше дәвам итә, бигрәк тә аваз ягы. Фонематик ишетү сәләте, сәнгатьле сөйләм теле көндәлек тормышта, сюжетлы рольле уеннарда үсә. “Мин” үсеш ала.

Акыл үсешләрендә тоткарлык күзәтелгән 5-6 яшьлек балаларның сөйләм механизмы тулысынча формалашып өлгермәгән,аларда импринтинг механизмы өстенлек итә.Балаларның хәтере,игътибары ихтиярсыз,шуңа күрә уенга,уйнап өйрәнүгә тагын да күбрәк йөз тотыла.Алар бик тиз арыйлар,вак кул моторикасы үсеше дә артта калган.Нәкъ менә шуларны истә тотып,аларга яңа-чит телләргә хас формаларны табигый юл белән,басым ясамый гына,кабат-кабат тыңлау аша үзләштерергә җирлек бирә.

**3.9 6 -7 яшьлек балаларның психик үсешенең яшь үзенчәлекләре.** Уендагы мөнәсәбәтләр эчтәлек һәм интонация ягыннан алган рольгә туры килүче сөйләм белән үрелеп бара.Балаларның реаль мөнәсәбәтләре вакытындагы сөйләм рольдәге сөйләмнән аерыла.Балалар социаль мөнәсәбәтләрне үзләштерә һәм олыларның төрле эшчәнлекләрдәге буйсынучанлык позициясен аңлый башлыйлар.Уен тирәлеген оештырганда,мәгънәви яктан “үзәк” һәм “периферия” аерымлану күзәтелә (“Сырхауханә” уенында табиб кабинеты,”Чәчтараш” уенында чәч кисү залы шундый үзәк,ә көтү залы уен тирәлегенең перифериясе сыйфатында була).Балаларның уендагы эш-гамәләре күптөрлеләнә. Төсне ,зурлыкны аңлау,кабул итү камилләшә бара. Зурлар төркемендә игътибар тотрыклылыгы үсә.Ирексез игътибардан аңлы игътибарга күчү күзәтелә. Сөйләм, шул исәптән аның аваз ягы камилләшү дәвам итә. Шигырьләр укыганда,сюжетлы-

рольле уеннар вакытында һәм көндәлек тормышта фонематик ишетү сәләте,сөйләмнең сәнгатьлелеге үсә,грамматик төзелеше камилләшә. Сүз байлыклары арта. Бәйләнешле сөйләм үсә. Зиһенгә алу объектларның катлаулы формаларын анализлау белән характерлана;фикерләү чараларын(схемалы,комплексылы кузаллаулар,цикллы үзгәрешләр турында кузаллаулар)үзләштерү белән бергә фикер йөртү сәләте үсә,гомумиләштерү күнекмәләре уйлап чыгару сәләте,тотрыклы игътибар,сөйләм,"Мин" образы үсә.

6-7 яшьлек акыл үсешләрендә тоткарлык күзәтелгән балаларның психосоциаль үсешләре үзенчәлекле булуын күздә тотып,эшчәнлек төрләрен еш алыштырып тору мөһим.Бала армасын өчен,эшчәнлекнең хәрәкәтләр белән үрелеп баруы,уен,биремнәрнең еш алмашынып торуы зарур.Шигырләрьләр сөйләгәндә,җырлар башкарганда эчтәлеккә мөнәсәбәттә хәрәкәтләр ясау мөһим.

**4. Балалар бакчасында тәрбияләнүче балаларның индивидуаль һәм яшь үзенчәлекләре**

Татарстан Республикасы Казан шәһәре «63 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы» Мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет белем бирү учреждениесендә 8 төркем формалашкан, 165 бала тәрбияләнә . Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе 12 сәгатьлек режим белән иртәнге 7.00-19.00 гә кадәр 5 көн эшли.Татар теле шөгыле балалар бакчасында уртанчылар төркеменнән өйрәтелә башлый , уртанчылар төркемендә атнага 3 тапкыр 15 минут режим вакытларында,зурлар төркемендә 1 шөгыль -25 минут,1 тапкыр режим вакытларында, мәктәпкә әзерлек төркемендә атнага 2 шөгыль -30ар минут,1тапкыр режим вакытларында.Кечкенәләр төркемендә дә режим вакытларында уен рәвешендә атнага 3 тапкыр-10-15 минут уздырыла.

## 5. Программа принциплары.

*Коммуникативлылык принцибы* – балаларны татар телен аралашу чарасы буларак куллануга әзерләүгә корылган. Телне фән буларак түгел, ә аралашу чарасы буларак өйрәтү;

*Тел өйрәтү, тәрбия һәм үстерү бурычларының бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тормышка ашыру принцибы;*

*Дәвамчанлык принцибы* – балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәптә эзлеклелекне күздә тоту;

*Белем бирү эшчәнлегенең мотивлашкан булу принцибы* – бала материалны үзе өчен кызык булганда, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килгәндә генә кабул итә һәм фикерли башлый. Телне өйрәтү процессында әкияти сюжетлар карау, кызыклы таныш геройлар (Акбай, Мияу) белән очрашу, уен элементларын куллану – тел материалын өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Телне аралашу, уен ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм алар тел материалын бик теләп үзләштерәләр.

*Индивидуальләштерү принцибы* – тел өйрәткәндә социаль шәхес сыйфатларын үстерүне күздә тоту. Балаларның яшь үзәнчәлекләрен исәпкә алу.

*Күрсәтмәлелек принцибы* – тел өйрәтүне көндәлек тормыштагы һәр төрле эшчәнлеккә бәйле рәвештә, аларның тирә-юньне танып белүенең төп чарасы булып торган уен аша үткәрү;

*Интеграция принцибы* – һәр сөйләм төренең үз үзәнчәлеген исәпкә алу, тәрбияче сөйләмен техник чаралар ярдәмендә (аудио, видеоязмада) тыңлау (аудирование), тел үзәнчәлекләрен төрле күнегүләрдә бирү, балаларның диалогик сөйләмен үстерү.

*Психологик рәхәтлек,иркенлек принцибы*– ни дәрәҗәдә психологик рәхәтлек,иркенлек тудырылса,чит тел өйрәнү теләге шул кадәр зуррак,нәтиҗәлерәк була.Бала

-армый;

-оялмый, үзен иркен тота;

- мавыгып эшли.

*Тел мохитына чумдыру принцибы* – эшчәнлек принцибы Куревина-Петерсонда баланың "яңа белем ачу"ын күз алдында тота.Чит тел өйрәнү процессында баланың төп эшчәнлек төре ул-сөйләм эшчәнлеге.Интеллектуаль үсешләрендә тоткарлык булган балалар белән татар телен өйрәнү барышында "яңа белем ачу" дигәндә,аның үз теленә хас булмаган чаралар аша аңлашуга ирешү мөмкинлеге күз алдында тотыла.Шундый ачышларга рухландыру

өчен,баланы,фәкать,туган телдә бер сүз дә әйтергә рөхсәт итми торган тел мохитенә “чумдыру” гына тәэмин итә ала.

*Минимакс принцибы* –шөгылләрне уңай кабул итү сакланган шартларда икенче телнең табигый өйрәнелүе материалның 100% үзләштерелүен тәэмин итә. Әмма бу үзләштерелгән материал барлык балалар тарафыннан да бердәй куланылышка кертелә дигән сүз түгел әлбәттә.Шуңа күрә шөгылләрне эчке активлык тәэмин ителерлек итеп оештырырга кирәк.

## 6.Татар телен өйрәтүдә кулланыла торган чаралар.

1.Эшчәнлек эшкәртмәләре, диагностик материаллар.
2.Тавышлы күрсәтмәлелек (һәр проект өчен аудиоязмалар, анимацион сюжетлар, мультфильмнар).
3.Картиналы һәм картиналы-дидактик күрсәтмәлелек (таратма һәм күрсәтмә рәсемнәр, җырлы-биюле уеннар, театр эшчәнлеге өчен материаллар.
4.Символик, график күрсәтмәлелек (пиктограммалар).
5.Күләмле күрсәтмәлелек (макетлар, муляжлар, уенчыклар)
6.Интерактив уеннар.
7.Эш дәфтәрләре.

## 7.Эш төрләре һәм формалары.

Программа бурычларын үтәүдә эш формаларыны, практик гамәли алымнарны, чараларның функциональ була алуына карап,балаларның яшь,сәламәтлек,үсеш үзенчәлкекләренә әһәмият биреп сайланды. Төп эш төрләре булып түбәндәгеләр тора:

1. Предметлар белән эш: тасвирлау, уенчык белән диалог төзү, уен һәм әкиятләрдә катнашу.
2. Рәсемнәр белән эш: тасвирлау, диалог.
3. Сюжетлы-рольле уеннар.
4. Әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар өйрәнү (аудиоязмага таянып).
5. Театральләштерү, сәхнәләштерү (бармак театры, битлекләр, костюмнар, театр күрсәтү (әти-әниләргә, башка төркем балаларына).
6. Хәрәкәтле уеннар: туп белән уеннар, “Командир” уены, әйлән-бәйлән уен, зарядка уеннары.
7. Иҗади һәм ситуатив уеннар: рольле уеннар, интервью, ситуатив күнегүләр.
8. Ситуатив, логик күнегүләрне ишетеп, аңлап эшләү.
9. Үстерелешле диалоглар (зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара аралашу).
10. Аудиоязмалар тыңлау, кушылып әйтү, җырлау, кабатлау, ишеткән сүзне рәсемдә табып күрсәтү.
11. Анимацион сюжетлар, мультфильмнар карау.
12. Интерактив уеннар.
13. Тормыш-көнкүрештә актив кулланыла торган сөйләм калыплары

## 8.Укыту методик комплектының эчтәлеге.

Һәр проект үз эченә түбәндәгеләрне ала:

1.тематик план;
2.эшчәнлек конспектлары;
3.балалар һәм әти-әниләр өчен эш дәфтәрләре;
4.аудиоязмалар;
5.анимацион күренешләр;
6.күрсәтмә, таратма материаллар;
7.диагностик материаллар

## 9.Татар теле өйрәтү программасы

**Программаның максаты һәм бурычлары:**

- Татар теленә кызыксыну уяту, аралашу теләге тудыру.
- Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгу.
- Балаларның көнкүрешкә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.
- Развитие социокультурной комптенции через обучение общению в специально смоделированной аутентичной языковой среде
- Развитие социализации через навыки групповой и индивидуальной работы.

**Бурычлар:**

- Сүз байлыгы булдыру, сөйләм күнекмәләрен формалаштыру, активлаштыру һәм камилләштерү, сөйләмне аралашу чарасы буларак файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү.
- Диалогта катнаша белү, көндәлек яшәештә аралашу, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту, хәтер, зиһен үстерү.
- Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен камилләштерү.

**Минимум бурычлар.**

Программа өч проектны һәм аларның төп максатларын һәм бурычларын үз эченә ала:

**“Минем өем” проекты (4-5 яшь).**

Максат: Баланың психофизиологик яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып,чит телдә аралашуга әзерләү аша шәхес буларак үсешен тәэмин итү һәм мәктәптә белем алуга әзерләү.

Бурычлар: 1.Татарча сөйләм нигезләренә өйрәтү,балаларда башка тел структурасының образын булдыру.

2. Иҗади фикер һәм психологик мөмкинлекләрне (хәтер,игътибар) үстерү.
3. Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү.
4. Бер – береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары тәрбияләү
5.Татар халкы кыйммәтләренә ихтирамлы мөнәсәбәт,кызыксыну формалаштыру

**“Уйный – уйный үсәбез” проекты (5-6 яшь).**

Максат: Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгу.

Бурычлар: 1. Сүз байлыгын арттыру, сөйләм күнекмәләре формалаштыру.

2. Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белү, көндәлек яшәештә аралашу.
3. Әдәпле итеп кара-каршы сөйләшә белү күнекмәләрен тәрбияләү.

**“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты (6-7 яшь).**

Максат: Балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.

Бурычлар: 1.Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү.

2. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.
3. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен камилләштерү

.

## 10.Показатели развития

**Үсеш күрсәткечләре**

Ребенок должен

1. понимать ситуативную речь на татарском языке;
2. уметь выполнять указания по ходу действия игры или другой деятельности;
3. уметь задавать простые вопросы,владеть простыми формами ответов;
4. уметь описывать предмет в простой форме (2-3 признака);
5. уметь рассказывать стихи,петь песенки на татарском языке

**11.Целевые ориентиры, сформулированные в ФГОС дошкольного образования по обучению татарскому языку**

Целевые ориентиры на этапе завершения дошкольного образования по обучению детей татарскому языку

· ребёнок проявляет уважение к людям другой национальности, к их культурным ценностям;

· ребёнок понимает речь на татарском языке, в пределах, изученных тем, задаёт вопросы на татарском языке;

· у ребёнка формируется мотивация к дальнейшему обучению татарского языка на этапе школьного обучения.

УМК:

В возрасте 4 – 5 лет объём словарного запаса: 62 слова татарского языка.

В возрасте 5 – 6 летобъём словарного запаса: 45 слова татарского языка.

В возрасте 6 – 7 летобъём словарного запаса: 60 слова татарского языка.

Перед выходом в школу объём словарного запаса составляет 167 татарских слов

**12.Балаларга татар теле өйрәтү программасы**

**<u>12.1 «Минем өем» проекты (4–5 яшь)</u>**

«Минем өем» проекты темалары («Гаилә», «Ашамлыклар», «Уенчыклар», «Саннар») буенча бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп, аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләре булдыру.

Балаларның тирә-юнь күзаллавын киңәйтә бару, югарыда күрсәтелгән темага караган сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру өстендә эшләү, татар телендә сөйләшә башлау теләге уяту.

Сүзләрне актив үзләштерүләренә ирешү өчен, әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлату һәм аларны дөрес әйтү күнегүләре эшләү. Иң якын кешеләр (эти, әни, бабай, әби, малай, кыз), яраткан уенчыклар (туп, машина, курчак, эт, песи куян, аю), ашамлыклар (алма, ипи, сөт, чәй) һәм саннар (бер, ике, өч, дүрт, биш) хисабына сүзлекне баету һәм активлаштыру. Өйрәнгән сүзләрне аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белү күнекмәләре булдыру (Алма бир. Мә, алма).

Бу кем? Бу нәрсә? сорауларына аңлап җавап бирергә өйрәтү.

– Бу кем? – Бу – эти.

– Бу нәрсә? – Бу – туп.

Нинди? соравын аңларга, дөрес җавап бирергә. өйрәтү

– Туп нинди? – Кечкенә.

– Машина нинди? – Матур.

Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауларны аңларга һәм сөйләмдә җавап кайтарырга өйрәтү (зур, матур, йомшак, кечкенә, чиста, әйбәт, пычрак, тәмле).

– Бу нәрсә? – Бу – туп.

– Туп нинди? – Туп түгәрәк (зур, матур, кечкенә, чиста, әйбәт).

Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны балаларның кабатлап әйтә белүләренә ирешү өстендә эшләү. Аларның өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган боремнәрне аңлап үти белүләренә ирешү (мә, бир, утыр, аша, эч, уйна, ю, ал).

– Мә куян.

– Бир куян.

Тәрбияче әйткән билге буенча предметны табу, күрсәтә белергә өйрәтү. Зур машина ал. Тәмле алма бир. Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша белергә өйрәтү, сүзләрне дөрес, урынлы куллану. Исәнме!

– Исәнмесез! Сау бул!

– Сау булыгыз! Мин – кыз.

– Мин – Оля. Мин – малай.

– Мин – Коля.

Таныш предметларның исемнәрен ныгыту, куелган сорауга раслау, инкарь итү сүзләрен (әйе, юк) дөрес кулланырга өйрәтү.

– Син Коля?
– Әйе.
– Син кыз?
– Юк, мин – малай.

Мин, син алмашлыкларын аңларга һәм урынлы кулланырга өйрәтү.

– Син кем?
– Мин – Коля.

Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар өйрәтү.

**12.2 “Уйный – уйный үсәбез” проекты. (5-6 яшьлек балалар өчен)**

«Уйный-уйный үсәбез» проекты темалары («Гаилә», «Ашам лыклар», «Уенчыклар», «Саннар», «Яшелчәләр», «Савыт-саба», «Киемнәр», «Шәхси гигиена», «Өй җиһазлары», «Бәйрәмнәр») буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп, аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләре булдыру.

Яңа сүзләр хисабына,шул исәптән,рус теленнән күчкән,редиска,бакладан,слива,... кебек сүзләр хисабына да баланың сөйләмен баету, тулыландыру (кишер, суган, бәрәңге, шалкан, кыяр, кәбестә, аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк, күлмәк, чалбар, бит, кул, баш, бармак, аяк, өстәл урындык, караватт, баллы, ничә, күп, нинди, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, сары, зәңгәр, нәрсә кирәк, юа, ки, киенә, сала, сал, йокла, хәерле көн, яратам, бар).

Санау күнекмәләрен ныгыту, сөйләмдә камилләштерү.

– Ничә туп?
– Ике туп.
– Ничә алма?
– Биш алма.

Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? сорауларын аңлап, мөстәкыйль рәвештә куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.

– Ничә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, шалкан, кыяр)? Сана.
– Ике (1–10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә , кыяр).

Раслау һәм инкарь итү сүзләрен (әйе, юк) ныгыту, урынлы куллану.

– Бу матур туп?
– Әйе, матур туп
– Син зур малай?
– Юк, мин – зур кыз.

Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә активлаштыру.

– Бу – зәңгәр тәлинкә.
– Бу күлмәк  чиста, матур, сары.

«Минем өем» проекты буенча өйрәнелгән боерык фигыльләрне  ныгыту (аша, эч, утыр, ю, уйна, йокла), яңа боерык фигыльләрне (ки, сал) сөйләмдә аңлап, дөрес куллана белергә  өйрәтү, активлаштыру.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегәләрдә камилләштерү.

– Нәрсә кирәк?
– Урындык (өстәл, карават) кирәк.
– Нинди урындык?
– Зур (кечкенә, сары, яшел, зәңгәр) урындык.
– Ничә урындык?
– Бер урындык.
– Мә бер зур урындык.
– Рәхмәт.

Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар өйрәтү.

**12.3 «Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар» проекты (6–7 яшь)**

**М а к с а т :** Балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.

**Б у р ы ч л а р :**

1. Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү.
2. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.
3. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен камилләштерү.

**6–7 яшьлек балаларга татар теле өйрәтү бурычлары**

«Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар» проекты темалары буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп, аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету. Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? сорауларын аңлап, мөстәкыйль рәвештә куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.

– Алло. Исәнме?!
– Исәнме! Син кем?
– Мин – Петя.
– Хәлләр ничек, Петя?
– Әйбәт. Хәлләр ничек, Аня?
– Әйбәт.
– Аня, нишлисең?
– Банан (ипи, алма) ашыйм. Петя, нишлисең?
– Сөт (лимонад, чәй) эчәм.
– Сау бул, Петя.
– Сау бул, Аня.

Фигыльләр белән лексиканы баету (аша – ашыйм, эч – эчәм, утыр – утырам, уйна– уйныйм, йокла – йоклыйм, бие – биим, җырла – җырлыйм, рәсем яса – рәсем ясыйм, укы – укыйм, йөгер – йөгерәм, чана шу – чана шуам, сикер – сикерәм, бар – барам)

– Саша сикер.
– Саша, син нишлисең?
– Мин сикерәм.

Җырлар, шигырьләр өйрәнү.

## 12.4 Акыл үсешләрендә тоткарлык булган балаларга татар телен өйрәтү буенча бердәм белем бирү челтәре

| Атна исемнәре | Төркем исемнәре | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1 нче зурлар төркеме | 2 нче зурлар төркеме | 3 нче мәктәпкә әзерлек төркеме | 4 нче уртанчылар төркеме | 5 нче зурлар төркеме | 6 нчы мәктәпкә әзерлек төркеме |
| **Дүшәмбе Понедельник** | | 10.20-10.50 | 9.00-9.30 | Режим вакытында | Режим вакытында | 9.40-10.10 |
| **Сишәмбе Вторник** | Режим вакытында | Режим вакытында | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Чәршәмбе Среда** | Режим вакытында | | Режим вакытында | Режим вакытында | Режим вакытында | 9.40-10.10 |
| **Пәнҗешәмбе Четверг** | 15.20-15.40 | Режим вакытында | | | | |
| **Җомга Пятница** | | | 10.25-10.55 | Режим вакытында | 10.00-10.25 | Режим вакытында |

## 12.5 Белем бирү эшчәнлеген планлаштыру

### 12.5.1 Беренче уку елы, уртанчылар төркеме

Режим моментларында

| № | Тема | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1. | Гаилә | 33 сәгать (1-33) |
| 2. | Ашамлыклар | 15 сәгать (34-48) |
| 3. | Уенчыклар | 29 сәгать (49-78) |
| 4. | Саннар | 6 сәгать (79-84) |
| 5. | Кабатлау | 6 сәгать (85-99) |

### 12.5.2 Икенче уку елы, зурлар төркеме

| Проект темалары | Тема | Эшчәнлек саны |
|---|---|---|
| 1.Кабатлау (1-2) | "Гаилә"-кабатлау<br>"Шалкан әкияте" | 1<br>1 |
| 2. Яшелчәләр (3-23) | "Кишер үстерәбез"<br>Баллы кишер<br>"Куян күчтәнәче"<br>"Бар матур бакча"<br>"Серле кәрзин"<br>"Бар матур бакча"<br>"Серле янчык"<br>"Яшелчәләр кибете"<br>"Серле кәрзин"<br>"Уйный-уйный эшлибез"<br>"Без хезмәт яратабыз"<br>"Төсле туплар"<br>"Төсләр дөньясы"<br>"Юл мажаралары"<br>"Төсләр дөньясы"<br>"Уңыш бәйрәме"<br>"Яшелчә салаты"<br>"Кем эшләми, шул ашамый"<br>"Яшелчә ю"<br>"Яшелчәләр кибете"<br>"Уйныйбыз да, җырлыйбыз да" | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 3.Ашамлыклар | "Ашханә" | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| (24-30) | “Ашамлыклар”<br>“Кибеттә”<br>“Аю кунакка килгән”<br>“Кунак килгән”<br>“Кем нәрсә ярата?”<br>“Кем нәрсә ярата?” өстәл тетры | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 4. Савыт-саба<br>(31-36) | “Туган көн”<br>“Курчак, Алиягә булыш”<br>“Чәй табыны әзерлибез”<br>“Өч аю”<br>“Төсле чынаяклар”<br>“Чисталыкта- матурлык” | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 5. Киемнәр<br>(37-44) | “Туган көнгә яңа киемнәр”<br>“Киемнәр кибете”<br>“Курчакны киендер”<br>“Без киенәбез”<br>“Киенергә ярдәм ит”<br>“Курчакларга булышабыз”<br>“Алия йокларга җыена”<br>“Кибеттә” | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 6. Шәхси гигиена<br>(45-49) | “Хәерле көн”<br>“Ягымлы сүзләр”<br>“Курчак белән уйныйбыз”<br>“Шаян уенчыклар”<br>“Өстәл театры “Өч аю” | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 7.Өй җиһазлары<br>(50-52) | “Маша һәм өч аю”<br>“Җиһазлар кибете”<br>“Ни өчен киемнәр югалган?” | 1<br>1<br>1 |
| 8.Бәйрәм<br>“Туган көн”<br>(53-66) | “Уйнарга яратабыз”<br>“Уенчыклар иле”нә сәяхәт<br>“Уйный-уйный үсәбез”<br>“Курчакның туган көне”<br>“Нәрсә бар?”, уенчыклар,яшелчә, өй җиһазлары<br>“Син нәрсә яратасың?”<br>“Бар- юк”<br>“Кем нәрсә ярата?”<br>Сабантуйга әзерләнәбез<br>“Без театр уйныйбыз”<br>Күңелле Сабантуй уеннары<br>“Биибез дә,җырлыйбыз да”<br>“Сабантуй бәйрәме”<br>Бездә Сабан туй | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br><br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |

**12.5.3 Өченче уку елы, мәктәпкә хәзерлек төркеме.**

| № | Тема | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Әйдәгез,танышабыз Т.б.б.э | 1 |
| 2 | Син кем? Т.б.б.э | 1 |
| 3 | Әйдәгез,танышабыз | 1 |
| 4 | Хәерле көн Т.б.б.э | 1 |
| 5 | Ягымлы сүзләр Т.б.б.э | 1 |
| 6 | Мияу адашкан | 1 |
| 7 | Син кем? Т.б.б.э | 1 |
| 8 | “Шалкан” әкиятен сәхнәләштерү Т.б.б.э | 1 |
| 9 | “Бу кем?” | 1 |
| 10 | Бу нәрсә?” Т.б.б.э | 1 |
| 11 | Кәз бүләкләре Т.б.б.э | 1 |
| 12 | Аю баласы дөнья белән таныша | 1 |
| 13 | Кем нишли? Т.б.б.э | 1 |
| 14 | Яшелчәләр Т.б.б.э | 1 |
| 15 | Бу нәрсә? | 1 |
| 16 | Дусларны сыйлыйбыз Т.б.б.э | 1 |
| 17 | Без кунак яратабыз Т.б.б.э | 2 |
| 18 | Батыр Мияу белән куркак Куян | 1 |
| 19 | Нишлисең? Т.б.б.э | 2 |
| 20 | Дусларны сыйлыйбыз Т.б.б.э | 1 |
| 21 | Әйдәгез,уйныйбыз | 1 |
| 22 | Без кунак яратабыз Т.б.б.э | 1 |
| 23 | Тату гаилә Т.б.б.э | 1 |
| 24 | Кунак килде | 1 |
| 25 | Дусларым белән сыйланабыз Т.б.б.э | 1 |
| 26 | Юмарт аю Т.б.б.э | 1 |
| 27 | Дусларым белән сыйланабыз | 1 |
| 28 | Кафеда Т.б.б.э | 1 |
| 29 | Әйдәгез,уйныйбыз Т.б.б.э | 1 |
| 30 | Кафега барабыз | 1 |
| 31 | Без кафеда Т.б.б.э | 1 |
| 32 | Кая барасың? Т.б.б.э | 1 |
| 33 | Кафеда сыйланабыз | 1 |
| 34 | Әниемнең туган көне Т.б.б.э | 1 |
| 35 | Кафега барабыз Т.б.б.э | 1 |
| 36 | Бәйрәм | 1 |
| 37 | Күңелле бәйрәм Т.б.б.э | 1 |
| 38 | Бергәләп уйныйбыз Т.б.б.э | 1 |
| 39 | Күңелле уеннар | 1 |
| 40 | Уйныйбыз Т.б.б.э | 1 |
| 41 | Бергәләп уйныйбыз Т.б.б.э | 1 |
| 42 | Спорт бәйрәменә әзерләнәбез | 1 |
| 43 | Спорт бәйрәмендә Т.б.б.э | 1 |
| 44 | Спорт бәйрәме Т.б.б.э | 1 |
| 45 | Бәйрәмгә барабыз | 1 |
| 46 | Мин барам Т.б.б.э | 1 |
| 47 | Көчлеләр,кыюлар,җитезләр Т.б.б.э | 1 |
| 48 | Казанда спорт бәйрәме | 1 |
| 49 | Спорт бәйрәмендә Т.б.б.э | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 50 | Казанда спорт бәйрәме Т.б.б.э | 1 |
| 51 | Уеннар эсафетасы | 1 |
| 52 | Эстафетада катнашабыз Т.б.б.э | 1 |
| 53 | Җәнлекләр спорт бәйрәмендә Т.б.б.э | 1 |
| 54 | Безнең дуслар | 1 |
| 55 | Үрдәк дусларын тапты Т.б.б.э | 1 |
| 56 | Безнең дуслар Т.б.б.э | 1 |
| 57 | Акбай чана шу | 1 |
| 58 | Чана шуам Т.б.б.э | 1 |
| 59 | Циркта Т.б.б.э | 1 |
| 60 | Әйдә,бие | 1 |
| 61 | Мин биим Т.б.б.э | 1 |
| 62 | Шаян кошлар Т.б.б.э | 1 |
| 63 | Мияуның бүлмәсен бизибез | 1 |
| 64 | Туган көнгә бүләк әзерлибез Т.б.б.э | 1 |
| 65 | Урманда зур концерт Т.б.б.э | 1 |
| 66 | Мияуның туган көне | 1 |
| 67 | Туган көн табынында Т.б.б.э | 1 |
| 68 | Акбай туган көнгә барырга әзерләнә Т.б.б.э | 1 |
| 69 | Күңелле сәяхәт | 1 |
| 70 | Күңелле сәяхәт Т.б.б.э | 1 |
| 71 | Туган көн Т.б.б.э | 1 |
| 72 | Күңелле сәяхәт | 1 |
| 73 | Күңелле сәяхәт Т.б.б.э | 1 |
| 74 | Урман китапханәсендә Т.б.б.э | 1 |
| 75 | Мәктәптә | 1 |
| 76 | Уку бүлмәсе Т.б.б.э | 1 |
| 77 | Күңелле сәяхәт Т.б.б.э | 1 |
| 78 | Өстәл театры “Теремкәй” | 1 |
| 79 | “Теремкәй” әкиятен сәхнәләштерү Т.б.б.э | 1 |
| 80 | “Теремкәй” Т.б.б.э | 1 |
| 81 | Өстәл театры “Кем нәрсә ярата?” | 1 |
| 82 | “Кем нәрсә ярата?” әкиятен сәхнәләштерү Т.б.б.э | 1 |
| 83 | Уйныйбыз Т.б.б.э | 1 |
| 84 | Белем иленә сәяхәт | 1 |
| 85 | “Могҗизалар кыры” Т.б.б.э | 1 |
| 86 | “Без инде хәзер зурлар-мәктәпкә илтә юллар” Т.б.б.э | 1 |
| 87 | “Без инде хәзер зурлар-мәктәпкә илтә юллар” | 1 |
| 88 | Уйныйбыз да,җырлыйбыз да Т.б.б.э | 1 |
| 89 | Тыңлагыз,тыңлагыз!Балалар сөйләшә Т.б.б.э | 1 |
| 90 | Мәктәпкә барабыз | 1 |
| 91 | Мәктәпкә барабыз Т.б.б.э | 1 |
| 92 | Мәктәпкә барабыз Т.б.б.э | 1 |
| 93 | Мәктәпкә барабыз | 1 |
| 94 | Сау бул,бакча!Исәнме,мәктәп! Т.б.б.э | 1 |
| 95 | Сау булыгыз,уенчыклар!Сау булыгыз,апалар! Т.б.б.э | 1 |
| 96 | Без инде хәзер зурлар,мәктәпкә илтә юллар | 1 |
| 97 | Күңелле уеннар Т.б.б.э | 1 |
| 98 | Уйныйбыз да уйныйбыз Т.б.б.э | 1 |
| 99 | Без әкият яратабыз | 1 |

**13. Төркемнәрдә коррекцион эш**

“Минем өем” проекты буенча коррекцион эш __________ уку елы

| Үткәрү Вакыты | № | Сораулар,биремнәр | Уеннар,күнегүләр,биремнәр | Төркем № | Баланың исеме |
|---|---|---|---|---|---|
| Декабрь | 1. | “Минем өем” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану.<br>Бу кем?Бу нәрсә?сорауларына җавап бирү | 1.Д.у. “Матур өйдә кем яши?”<br>2.Д.у. “Кем юк?” (әйе-юк)<br>3.Д.у. “Исемен әйтсәң-бирәм”(гаилә әгъзалары, уенчыклар)<br>4.<br>5.Д.у.”Бу кем?Бу нәрсә?” | | |
| Январь | 2. | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме,сау бул,рәхмәт”) | 1.Ситуатив күнегү “Куян аюга кунакка килә”<br>2. Ситуатив күнегү “Сыйла” | | |
| Февраль | 3. | Боерыкны бирә белү (кил,утыр,аша,эч,бир,мә) | 1.Д.у.”Командир”<br>2.Д.у.”Мин әйтәм-син эшлә”<br>3.”Шаян уенчыклар”<br>4.Д.у.”Ничә җиләк?<br>5.Д.у.Фразовый конструктор | | |
| Март | 4. | Тирә-юньдәге предметларның сыйфатын,күләмен белдерә торган схзләрне аңлап,сөйләмдә куллану. | 1.Д.у.”Бу нәрсә, нинди, ничә?”<br>2. Д.у.Фразовый конструктор<br>3.Д.у.”Дөрес сана”<br>4. Ситуатив күнегү”Курчакка бүләк” (зур- кечкенә) | | |
| Апрель | 5. | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү,чакыру,сыйлау,сорап алу,тәкъдим итү,инкаръ итү,раслау) | 1.Ситуатив күнегү “Әйдә, танышыйк”<br>2. Ситуатив күнегү “Кунак каршылау”<br>3. Ситуатив күнегү “Кунак сыйлау”<br>4. Ситуатив күнегү “Уенчык сорап ал”<br>5.Д.у.Фразовый конструктор | | |
| Май | 6. | Мониторинг | | | |

“Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча коррекцион эш __________ уку елы

| Үткәрү вакыты | | Сораулар,биремнәр | Уеннар,күнегүләр,биремнәр | Төркем № | Баланың исеме |
|---|---|---|---|---|---|
| Октябрь | 1 | “Минем өем” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану.Бу кем? Бу нәрсә? сорауларына җавап бирү. | 1.Д.у.”Матур өйдә кем яши?”<br>2. Д.у.”Исемен өйтсәң-бирәм”<br>3.Д.у.Фразовый конструктор | | |
| Ноябрь | 2 | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү,чакыру, әйтү, сыйлау,сорап алу, тәкъдим итү,инкаръ итү,раслау) | 1.Ситуатив күнегү “Кунак каршылау”<br>2. Ситуатив күнегү "Кунак сыйлау”<br>3. Ситуатив күнегү “Әйдә,танышыйк2 | | |
| Декабрь | 3 | “Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. Бу кем?Бу нәрсә?Нинди?Ничә?сорауларына җавап бирү | 1.Д.у.”Бу нәрсә?”<br>2.Д.у.”Бу кем?”<br>3.Д.у.”Нинди,ничә?”<br>4. Д.у.””Кем юк?” | | |
| Январь | 4 | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме,исәнмесез,сау бул,сау | 1.Ситуатив күнегү “Яшелчәләр кибете” | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | булыгыз,рәхмәт,хәерле көн,хәлләр ничек?әйбәт”) | 2. Ситуатив күнегү “Телефоннан сөйләшү” | | |
| Февраль | 5 | Төсләр дөньсында”<br><br>Боерыкны бирә белү (килмонда,утыр,сикер,уйна,ки, сал,аша,йокла,эч,бир,мә) | 1.Д.у.”Мин әйтәм- син эшлә”<br>2.Д.у.”Мияу,мияу,нинди?” | | |
| Март | 6 | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау куя белү (нәрсә кирәк? нинди?ничә?син кем?бу кем?бу нәрсә?) | 1.С.р.уен “Киемнәр кибете”<br>2. С.р.уен “Супермаркет”<br>3. С.р.уен “Туган көн”<br>4.Д.у. “Парын тап “ (төсләр) | | |
| Апрель | 7 | Аралаша белү (ягымлы сүзләр куллану“исәнме,исәнмесез,сау бул,сау булыгыз,рәхмәт,хәерле көн,хәлләр ничек?әйбәт” тәкъдим итү,инкаръ итү,раслау,) | 1Ситуатив күнегү “Таныш булыйк”<br>2.Ситуатив күнегү “Кәрзиндә нәрсә бар”<br>3.Ситуатив күнегү “Куяннарга киенергә булыш”<br>4. Ситуатив күнегү “Аюлар яңа өйгә кучә,булыш”<br>5. Ситуатив күнегү “Савыт сабалар бүләк итәбез” | | |
| Май | 8 | Мониторинг | | | |

## 14.МЕТОДИК КИҢӘШЛӘР

Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгының “Мәктәпкәчә учреждениеләрдә татар теле, рус, ана телләрен яхшырту чаралары турындагы” 2001 елның июнь аенда чыккан 463 номерлы карары нигезендә татар теле өйрәтү эшчәнлекләре зурлар төркемендә атнага 1,мәктәпкә әзерлек төркемендә - 2 тапкыр белем бирү эшчәнлеге,уртанчылар төркемендә 3 тапкыр, зурлар, мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә атнага 1әр тапкыр режим вакытларында уздыру каралган. Методик кулланмаларда белем бирү эшчәнлегенең конспектлары бирелгән. Тәрбияче ел дәвамында, үзе иҗади якын килеп, укыту методик кулланмада бирелгән тематик планга таянып, мультфильмнар, анимацион сюжетлар, “Әкият илендә” тапшыруын кулланып, индивидуаль эшне дә кертеп, кирәкле күләмдә көндәлек план төзи.

Телгә өйрәтүнең төп формасы һәм чарасы булып белем бирү эшчәнлеге алына. Ул системалы рәвештә план буенча үткәрелә. Өйрәнелгән сүзләр, сүзтезмәләр, диалоглар эшчәнлектән тыш уен вакытларында активлаштырыла һәм ныгытыла, көндәлек аралашуда кулланыла.

Яңа сүзләрне, сүзтезмәләрне, ситуацияләрне балалар аңламаган очракта, тәрбияче рус телендә сөйли.

Пиктограммалар мәктәпкә әзерлек төркемендә, яңа сүзләр (фигыльләр) белән беренче тапкыр таныштырганда гына кулланыла.

Бала татар телендә сүзне дөрес әйтмәгән очракта, тәрбияче баланы тыңлап сүзнең дөрес үрнәген бирә. Балалардан авазларның дөрес әйтелешен катгый таләп итмәскә кирәк.

Тәрбияче сөйләмендә акцент, җирле диалект, аваз кимчелекләре булмаска тиеш.

Тәрбияче сүзлек белән эшләгәндә татар һәм рус телләре өчен уртак сүзләргә таяна ала.

Тәрбияче үзенең эшенә иҗади якын килергә, төрле алымнар, чаралар эзләп, аларны кулланырга тиеш.

Укыту-методик комплекты кысаларында, лексик минимумны үзләштергән очракта, эшчәнлектә планлаштырылган уеннарның эчтәлеген үзгәртү, яңа алымнар кертү, баету хуплана.

Төркемнәрдә балаларның һәм тәрбиячеләрнең татар телендә аралашулары һәрдаим булырга тиеш. Эшчәнлектә өйрәнелгән тел материалы, режим моментларында, уен эшчәнлеге аша (ситуатив күнегүләр, сюжетлы рольле уеннар, үстерелешле диалоглар, сәхнәләштерү һ. б.) ныгытыла.

Рус телле балаларны татарча сөйләшергә өйрәткәндә балалар бакчасы коллективы һәм эти-әниләрнең бердәм позициядә булуы уңай нәтиҗә бирә.

## 14.1 Сүзлек белән эшләү.

Балаларны татар телендә сөйләшергә һәм аралашырга өйрәтү билгеле бер күләмдәге сүз байлыгы булдырудан башлана.

Яңа сүзләр үзләштерү процессында махсус сайлап алынган күнегүләр төп чара булып тора. Юнәлеше һәм характеры ягыннан лексик күнегүләрне икегә бүлеп карыйлар: әзерлек күнегүләре һәм сөйләм күнегүләре.

*Әзерлек күнегүләре* балаларны яңа сүзләрне файдаланып сөйләргә әзерли. Бу күнегүләр лексик берәмлекләрне хәтердә калдырырга ярдәм итәләр.

*Сөйләм күнегүләре* лексик күнегүләрнең бер төре буларак, үзләштерелгән лексик берәмлекләр җирлегендә ситуацияләргә бәйле сөйләм эшчәнлеген барлыкка китерәләр.

Яңа сүз өйрәтү төп методик алымнарның берсе булып тора:

-яңа сүз тәрбияче тарафыннан ачык, төгәл итеп күрсәтмә рәсем ярдәмендә әйтелә;
-аудиоязмадан тыңлатыла, кабатлатыла;
-ишеткән сүзне бала рәсемннән табып күрсәтә һәм әйтә;
-сүзләр тизрәк истә калсын өчен сүз кат-кат әйттерелә, аңлашылмаган очракта, аның русча тәрҗемәсе бирелә;
-төрле эш формаларында (пышылдап, күмәкләп, төркемнәргә бүленеп, хәрәкәтләнеп әйтеп) өйрәтелә;
-уеннар кулланып (“Кайтаваз”...) ныгытыла;
-яңа сүз, таныш булган сүзләр белән грамматик конструкцияләрдә ныгытыла, мәсәлән: зур туп, чиста туп;
-аралашуда кулланыла (бала өйрәнгән яңа сүзләрне, конструкцияләрне бары аралашуда аңлап куллана).
-бала теге яки бу сүзне аның төгәл мәгънәсен аңлап үзләштереп калсын өчен телдән мондый күнегүләрне үткәрергә мөмкин: -*Бу туп? - Әйе, (бу туп.)*

*-Бу песи? (туп күрсәтелә) - Юк, (бу туп.)*

-өйрәнелгән сүзләрне хәтердә калдыру максатыннан төрле уеннар оештырырга була: “Исемен әйтсәң бирәм”, “Мин күрсәтәм, син әйт”, “Сорап ал”, “Серле кәрзин” һ.б..

Баланың сөйләмен оештыру өчен исемнең алмашлык (мин, син, бу), сан (1 дән 10 га), сыйфат (тәм, күләм, төс, эчке сыйфатлар) һәм фигыль белән бәйләү грамматик конструкцияләре кулланыла.

Фигыль белән таныштыру боерык фигыльләрдән башлана (бар, сикер, аша һ.б.).

Уртанчылар төркемендә балаларга боерык фигыльләрне аңлап үтәүләрен таләп ителә.

Зурлар төркемендә балалар кайбер боерыкларны үзләре бирә (сикер, аша, уйна) һәм аңлап үтиләр.

Мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә балалар үзлектән Нишли? Син нишлисең? сорауларын бирәләр һәм аңлап җавап кайтаралар.

Укыту методик комплектының төп асылы булып аралашуга чыгу тора. Аралашуга чыгу өчен диалогик сөйләмнең әһәмияте бик зур. Диалогик сөйләмгә өйрәткәндә гадидән катлаулыга дигән дидактик принципка таянып эшләү кулай.

Диалогик сөйләмдә иң отышлы алым – сорау-җавап рәвешендә (сорау-информация алу берәмлеге) һәм теләк белдерә торган: теләк, үтенү, тәкъдим итү, ризасызлык төсмере булырга мөмкин. Еш кына сораудан соң, әңгәмәдәшнең җавап репликасы; килә: *Бу кем?- Бу эти;* раслау рәвешендә: *Бу эти?- Әти;* инкарь рәвешендә: *Бу әни?- Юк,( бу эти).* Реплика- җавап сорау рәвешендә дә булырга мөмкин: *Нинди эти?* Бу вакытта әңгәмәдәшнең җавабы тулы да, ким дә булырга мөмкин: *Матур эти;* яисә: *Матур.*

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга ситуатив - тематик принцип нигезендә, диалогик сөйләмне үстерү буенча түбәндәге типтагы күнегүләр тәкъдим итәргә мөмкин:

- уен ситуацияләрендә катнашу;
- тәкъдим ителгән үрнәк буенча кечкенә диалоглар төзү;
- тематик диалоглар төзү;
- сәхнәләштерүдә катнашу;
- рольләргә бүлеп сөйләү.

Диалоглар белән эшләү коммуникатив юнәлештә алып барылырга тиеш. Тәрбияче аларның балалар сөйләменә кирәкле формаларын эшләргә һәм төрле шартларда куллану мөмкинлеген исәпкә алырга тиеш. Тәрбияче, сөйләмгә эмоциональ бизәлеш өстәү өчен, төрле формаларны кулланырга; эш эчтәлегенә туры килә торган интонация, ишарәләр, мимикалардан файдаланырга һ.б. өйрәтергә тиеш.

Шул ук вакытта, диалогны сорау бирү һәм аңа җавап алу дип кенә уйларга ярамый. Балаларны диалогик сөйләмгә хас булган башка (сорау һәм җаваплардан тыш) ситуацияләр, репликалар, көндәлек аралашу формаларына да өйрәтергә кирәк.

Диалог үрнәкләре:

Исәнләшү: *Исәнме, Оля! – Исәнме, Коля.*

Саубуллашу: *Сау бул, Оля. – Сау бул, Коля.*

Танышу: *Мин- Оля. – Мин -Коля.*

Чакыру: *Оля, кил монда.*

Рәхмәт белдерү: *Мә, курчак. – Рәхмәт.*

Сорау- уңай җавап: *Син малай? – Әйе, (мин малай.)*

Сорау – кире җавап: *Син малай? – Юк, (мин кыз.)*

## 14.2Аралашуга чыгу чаралары- аудиоязмалар, эш дәфтәрләре, анимацион сюжетлар.

**Аудиоязмалар** яңа сүз өйрәтү, сөйләм үрнәкләре үзләштерү, уеннар, кыска җырлар өйрәтү, өстәл театры күрсәтү вакытларында куллану өчен төзелде. Аларны һәр эшчәнлектә куллану мөһим түгел.

**Эш дәфтәрләре** эшчәнлектә өйрәнелгән материалны ныгытуны күздә тотып төзелде. Дәфтәрләр белән эшләгәндә балалар кабатлыйлар,тәрбияче белән аралашалар. Балалар үзләренең эш дәфтәрләрен өйгә алып кайтып өйрәнелгән материалны кабатлый алалар. Бу дәфтәрләр белән әти-әниләр дә, төркем тәрбиячеләре дә эшли ала, чөнки биремнәр рус телендә язылды.

Дәфтәрдәге эшнең нәтиҗәсе уртанчылар төркемендә сүзне ишетеп, аңлап, предметларны табып, парлаштырып, чагыштырып, аларның сыйфатын, санын билгеләүгә китерсә, зурлар төркемендә балаларны үзара аралашуга этәрә һәм бу мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә дәвам итә. Иң катлаулы биремнәр мәктәпкә әзерлек төркеме өчен төзелгән. Бу төркемдә хәрәкәтне белдерүче сүзләр, яки фигыльләр күп кулланыла. Балаларны ситуацияләргә куеп, сораулар биреп диалогка этәрәбез. Берүк вакытта, фигыльләр боерык формада (утыр, уйна һ.б.), 3-нче зат алмашлыгына тәңгәл формада (яки утыра, укый, шуа, ашый һ.б.), һәм дә инде үзе турында 1-нче зат алмашлыгын кулланып өйрәтелә (уйныйм, утырам, барам, эчәм һ.б.). Балалар бер-берсенә, өлкәннәргә сораулар бирергә өйрәнәләр: бу нәрсә, нишли, син нишлисең, нәрсә кирәк, нинди һ.б. Җөмләләр төзү баланың уйлавын таләп итә, чөнки алар 3-4 сүздән торалар. Мәсәлән: Аю караватта йоклый. Куян чана шуа. Песи бит юа һ.б.. Мәктәпкә әзерлек төркемендә өченче бирем җыр формасында бирелә.Бу биремнәрне интерактив такта һәм экраннарда эшләп була.Балаларга катлаулы булган биремнәрне күмәк үтәү мөмкин.

**Анимацион сюжетлар** балаларның белгән сүз байлыгына, яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелде. Сюжетны караганнан соң, балалар белән әңгәмәләр үткәрелә, алда өйрәнелгән уен ситуацияләрен кабатларга тәкъдим ителә.

“Татарча сөйләшәбез” укыту методик комплектына нигезләнеп эшләнгән “Әкият илендә” телевизион тапшыруын балаларны татар теленә өйрәткәндә карарга тәкъдим ителә.

## 14.3 Тематик план

### «Минем өем» проекты (4–5 яшь)

**Лексик минимум** – якынча 62 сүз.

**Үзләштерү өчен тәкъдим ителгән сүзләр:** әти, әни, кыз, малай, мин, исәнмесез, исәнме, сау булыгыз, сау бул, эт, песи, әйе, юк, әби, бабай, әйбәт, ипи, алма, сөт, чәй, рәхмәт, мә, тәмле, кил монда, утыр, бир, аша, эч, туп, зур, кечкенә, матур, курчак, куян, аю, хәлләр ничек, уйна, пычрак, чиста, ю, бер, ике, өч, дүрт, биш, утырыгыз, басыгыз, ал; Ничә? Нинди? Бу кем? Кем юк? Син кем?

**Сөйләм үрнәкләре:**

-Бу кем?
-Әти (әни, бабай, әби, кыз, малай).

-Кем юк?
-Әти (әни, бабай, әби, малай, кыз).

-Исәнмесез.
-Син кем?
-Мин Коля (Оля).
-Мин малай.
-Сау булыгыз!

-Исәнме, әни (әти, бабай, әби, кыз, малай, Мияу, Акбай).
-Сау бул, әни (әти, бабай, әби, кыз, малай)

-Кем анда?
-Мин песи. Мин Мияу.
-Кил монда.
-Мин эт. Мин Акбай.
-Кил монда.

-Син Коля?
-Әйе, Коля.
-Син малай (кыз)?
-Әйе (юк).

-Әти? (әни, бабай, әби, кыз, малай).
-Әйе.
-Әни? (әти, бабай, әби, кыз, малай).
-Юк.

-Малай?
-Юк, кыз.
-Кыз?
-Әйе, кыз.

-Хәлләр ничек?
-Әйбәт
-Бу нәрсә?
-Аю (курчак, куян, туп).
-Аю (курчак, куян, туп) нинди?
-Аю (курчак, куян, туп) зур (матур, кечкенә, әйбәт).

- Аю (курчак, куян, туп) нинди?
- Аю (курчак, куян, туп) зур (кечкенә, матур, әйбәт).

-Аю (курчак, куян, туп)?
-Әйе.
-Курчак (аю, куян, туп)?
-Юк.

-Бу нәрсә?
-Аю (курчак, куян, туп).
-Мә, аю (курчак, куян, туп). Уйна.

-Коля, кил монда. Уйна.
-Оля, кил монда. Уйна.

- Аю (курчак, куян, туп) бир.
- Аю (курчак, куян, туп) нинди?
- Аю (курчак, куян, туп) зур.
- Аю (курчак, куян, туп) кечкенә.

- Мә, зур аю (курчак, куян, туп).
- Мә, кечкенә аю (курчак, куян, туп).
-Аю (курчак, куян), кил монда. Аша (утыр, эч, уйна).

-Коля (Оля), аю (курчак, куян, туп) ю.

-Туп (курчак, куян, аю) нинди?
-Туп (курчак, куян, аю) пычрак (чиста).
-Туп ю.
- Туп чиста?
- Юк, туп пычрак.
(Әйе, туп чиста).

Ю, ю, ю – туп (курчак, аю, куян) ю.

-Ничә?
-Бер (ике, өч, дүрт, биш) алма.

-Ничә малай?
-Бер (ике, өч, дүрт, биш) малай.
-Ничә кыз?
-Бер (ике, өч, дүрт, биш) кыз.
-Өч?
-Юк.
-Ике?
-Әйе.

-Ничә аю (туп, курчак, куян)?

-Бер (ике, өч, дүрт, биш) аю.

**Уйный-уйный үсәбез» проекты (5–6 яшь)**

**Лексик минимум** – якынча 45 сүз.

**Үзләштерү өчен тәкъдим ителгән сүзләр:** кишер, нинди, баллы, ничә, суган, бәрәңге, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кыяр, кәбестә, кызыл, сары, яшел, кирәк, юа, нәрсә кирәк, аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк, зәңгәр, күлмәк, чалбар, ки, сал, йокла, бит, кул, өстәл, урындык, караватъ, яратам, бар, хәерле көн, күп; Нәрсә бар? Бу нәрсә?

Уртанчылар төркемендәге темалар (гаилә, ашамлыклар, уенчыклар, саннар) ел дәвамында кабатлана.

**Сөйләм үрнәкләре:**

-Бу нәрсә?
-Кишер.
-Мә, кишер.

-Нинди кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)?
-Зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)
-Мә, зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)
-Рәхмәт.

-Зур кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)

-Кечкенә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)
-Чиста кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)
-Пычрак кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)

-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) нинди?
-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) тәмле, зур (кечкенә), матур, чиста (пычрак)

-Оля, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) бир.
-Мә, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә,кишер).
-Рәхмәт.

-Коля, (1-10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр) бир.
-Мә, (1-10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр).
-Сау бул, Коля.

-Ничә кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер)?
-Бер (1-10) кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер).
-Кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) пычрак.

-Бу туп.
-Туп (алма) нинди?
-Туп (алма) сары (кызыл, яшел)

-Нинди туп (алма) юк?
-Кызыл (сары, яшел) туп (алма) юк.

-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) кирәк?
-Кирәк.

-Коля, нәрсә кирәк?
-Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) кирәк.
-Нинди кыяр?
-Яшел (тәмле, чиста) кыяр.

-Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) пычрак.
-Мә, кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) ю.

-Оля кыяр ( суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) юа.

тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй)

-Нәрсә кирәк?
-Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) кирәк.
-Нинди аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге)?
-Тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге).
-Мә, аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) аша (эч).

-Рәхмәт. Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) тәмле.

-Кашык (тәлинкә, чынаяк) бир.
-Нинди кашык (тәлинкә, чынаяк)?
-Зур (кечкенә, сары, яшел, кызыл, зәңгәр).
-Ничә кашык (тәлинкә, чынаяк)?
-(1-10 га) кашык (тәлинкә, чынаяк).
-Мә, (1-10) кашык(тәлинкә, чынаяк).

-Мә, кызыл (сары, яшел, зәңгәр). чынаяк (тәлинкә, чынаяк).

яшел (кызыл, сары, зәңгәр) күлмәк (чалбар).

чиста күлмәк (чалбар).
матур күлмәк (чалбар).

күлмәк (чалбар) юк.

-Оля, күлмәк (чалбар) бир.
-Нинди күлмәк (чалбар)?
-Сары (кызыл, яшел, зәңгәр) күлмәк (чалбар).
-Ничә күлмәк (чалбар)?
-Бер (1-10) күлмәк (чалбар).

-Курчак, чалбар (күлмәк) ки (сал).

-Оля, чалбар (күлмәк) бир.
-Мә, чалбар (күлмәк).
-Рәхмәт. Курчак, мә, чалбар (күлмәк) ки (сал).
-Курчак, йокла.

-Хәерле көн.
-Мә су, бит (кул) ю.

-Бит (кул) чиста.

-Зур аю, мә зур караватъ (өстәл, урындык).
-Кечкенә аю, мә кечкенә караватъ (өстәл, урындык).

-Нәрсә кирәк?
-Караватъ (өстәл, урындык) кирәк.
-Нинди караватъ?
-Зур (кечкенә, сары, яшел, зәңгәр) караватъ.
-Мә, зур караватъ.
-Рәхмәт.

-Мин алма (ипи, сөт, чәй, ботка, аш, кыяр, кәбестә, бәрәңге, кишер) яратам.

-Мин Коля(ны) (Оля(ны) яратам.

-Мин курчак(ны) (аю(ны), песи(не), эт(не), куян(ны) яратам.

-Нәрсә бар?
-Туп (курчак) бар.
-Нәрсә юк?
-Туп (курчак) юк.
“Бар”, “Юк” сүзләрен кулланып “Гаилә”, “Яшелчә” “Уенчыклар” темаларын кабатлау.
Диалогларны кабатлау.
“Кибетле” уеннары.

**“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты (6-7 яшь)**

**Лексик минимум** якынча 60 сүз.

**Үзләштерү өчен тәкъдим ителгән сүзләр:** син кем, хәерле көн, тычкан, йокла, утыр, аша, эч, ашыйм, эчәм, уйна, уйныйм, утырам, барам, сикер, сикерәм, йөгер, төлке, йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, этәч, үрдәк, чана, шу, шуам, бие, биим, ак, кара, җырла, җырлыйм, рәхмәт, китап укы, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр; Бу кем? Бу нәрсә? Нишли? Нишлисең? Кая барасың? Син нишлисең? Нәрсә яратасың?

**Проектның эчтәлеге** уртанчылар, зурлар төркемендә өйрәнгән сүзләргә таянып аралашуга корылган.

**Сөйләм үрнәкләре:**
-Хәерле көн, әни (әти, бабай, әби).
-Хәерле көн, Оля (Коля).

-Мияу, нишлисең?
-Ашыйм.
-Акбай, нишлисең?
-Эчәм.

-Оля (Коля), нишлисең?
-Уйныйм.

-Кая барасың?
-Кафега барам.
-Син нишлисең?
-Мин бәрәңге ашыйм (чәй эчәм, уйныйм, барам, утырам, йоклый)

Туп, туп
Матур туп.
Сикер-сикер,
Матур туп.

-Йөгер! Син нишлисең?
-Мин йөгерәм.

-Мин чәк-чәк ашыйм.
-Мин өчпочмак ашыйм.

-Сиңа ничә яшь?
-6 яшь.

-Мин бүре. Мин зур, матур, чиста.

Әтәч зур, матур
Тавык кечкенә, матур

-Син кем?
-Мин үрдәк.

Мин чана шуам.

-Аю,  бие!

-Оля кызыл шар ярата?
-Юк.
-Оля яшел шар ярата?
-Әйе

-Син нишлисең?
-Мин җырлыйм.
рәхмәт

рәсем ясыйм-алма ясыйм
мәктәп
-Кем укый.
-Мин укыйм.

Терем-терем, теремкәй,

Зур түгел, кечкенә.
Теремкәйдә тычкан яши.
Теремкәйдә куян яши.
Теремкәйдә бүре яши.
Теремкәйдә төлке яши.
Теремкәйдә аю яши.
Алар бик дус.

-Кәҗә кая?
-Кәҗә кәбестә ярата.

-Мин ипи яратам. Песи, син нәрсә яратасың?
-Мин сөт яратам. Сөт тәмле.

-Мә, кәҗә, ботка аша.
-Юк, кәбестә яратам. Кәбестә тәмле.

## 14.4МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАРНЫҢ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛӘШӘ (АРАЛАША) БЕЛҮ КҮНЕКМӘЛӘРЕН ТИКШЕРҮ.

Балаларның татар телендә аңлау һәм сөйләшә (аралаша) белү күнекмәләрен уку елы башында (октябрь ае) һәм уку елы ахырында (апрель аенда) тикшерелә. Уртанчылар төркеме балалары белән тикшерү уку елы ахырында үткәрелә. Уку елы уртасындатематик тикшерү (декабрь, январь) үткәрергә мөмкин.

Тикшерүне һәр бала белән аерым, 1–2 бала катнашында, ә йомгаклау эшчәнлеге булганда барлык балалар белән бергә дә үткәрергә була. Тикшерү вакыты 10-15 минутан артмаска тиеш.

Биремнәр балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып үткәрелә, уен-бирем рус телендә аңлатыла. Биремнәр мавыктыргыч һәм кызыклы булырга тиеш. Сораулар ачык, төгәл итеп, интонация белән бирелә. Тикшерүче балаларның җавабын тыңлаганда елмаеп, кирәк булса җавапны дөреслэп, бала әйтә алмаганда булышырга тиеш.

Тикшерү барышында яңа материал бирелми. Тикшерүне эш дәфтәрләре, таратма, күрсәтмә рәсемнәр, интерактив тактада, проекцион техника экранында уеннар кулланып үткәрергә дә була.

Биремнәр, уеннар өчен кирәк булган күрсәтмәлелек алдан әзерләнеп куелган булырга тиеш. Тикшерүче һәр биремгә аерым балл куеп бара. Тикшерү ахырында баллар саны кушыла һәм 5 кә бүленә. Шулай итеп, гомуми нәтиҗә ясала.

1 раздел

**Уку елы ахырында уртанчылар, уку елы башында зурлар төркеме балаларының**
**“Минем өем” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.**

| № | Баланың исеме, фамилиясе | Биремнәр | | | | | Нәтиҗә | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | баллар | дәрәҗә |
| | | “Минем өем” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча дүрт – биш рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | Ягымлы сүзләр куллану (“Исәнме”, “Исәнмесез”, “Сау бул”, “Сау булыгыз”, “Хәлләр ничек?”, “Рәхмәт”) | Боерыкны аңлап үтәү һәм куллана белү (кил, утыр, уйна, ю, аша, эч) | Тирә - юньдәге предметларның сыйфатын, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану. | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) | | |
| | | | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | |

**Нәтиҗәләрне билгеләү**

| | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә 2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, сорауларга җавап бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә 2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, аралашуда бик үк актив түгел. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә 1 дән 1,9 га кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

**Балаларның татар телендә аралаша белү дәрәҗәсен тикшергәндә кулланырга мөмкин булган биремнәр.**

1. **“Минем өем” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча дүрт – биш рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла)**

**1. Дидактик уен. "Бу кем?"**(Івариант)
(Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай)
Уен эчтәлеге: Өй рәсеме. Өй тирәсендә гаилә әгъзалары рәсемнәре (комплекттагы күрсәтмә рәсемнәр). Тәрбияче рәсемнәргә күрсәтеп сорый: Бу кем? ("Әни"...).
**2. Дидиктик уен "Кем юк?"** (II вариант)

(Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай)
Уен эчтәлеге: Уен шул ук рәсемнәр кулланып үткәрелә. Тәрбияче бер рәсемне алып куя. Баладан сорый: "Кем юк?" ("Әби"...)
Уенны интерактив тактада, проекцион техника экранында, бала белән бала арасында диалог формасында да үткәрергә була.
**3.Дидактик уен "Кәрзиндә нәрсә бар?"**

(Лексика: ипи, алма, сөт, чәй)
Уен эчтәлеге: Мияу кәрзин белән ашамлыклар алып килгән. Мияу ашамлык муляжларына күрсәтә, исемен сорый: "Бу нәрсә?" ("Алма"...)
**4.Дидактик уен "Нәрсә юк?"**
(Лексика: ипи, алма, сөт, чәй)
Уен эчтәлеге: Мияу бер ашамлык муляжын яшереп куя: "Нәрсә юк?". Бала нәрсә юклыгын әйтергә тиеш. ("Алма"...)Уенны рәсемнәр кулланып та үткәреп була.
**5.Дидактик уен "Мин әйтәм, син күрсәт һәм әйт"**

(Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай, куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи, ипи, алма, сөт, чәй).
Уен эчтәлеге: Балага уенчык яисә уенчык рәсемнәре бирелә. Бала, тәрбияче әйткән уенчыкны яисә уенчык рәсемен табып күрсәтергә һәм исемен кабатлап әйтергә тиеш.
**6.Дидактик уен "Исемен әйтсәң бирәм"**

(Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай, куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи, ипи, алма, сөт, чәй).
Уен эчтәлеге: Өстәлдә уенчыклар яисә рәсемнәр. Тәрбияче балага уенчыкны (рәсемне) күрсәтә, сорый: "Бу нәрсә?" - "Алма"... ; "Бу кем?" - "Әти"... Бала дөрес җавап бирсә, аңа уенчыклар, яисә таратма рәсемнәр бирелә.
**7.Дидактик уен "Серле янчык"**

(Лексика: куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи)
Уен эчтәлеге: Балага уенчыклар күрсәтелә, исемнәрен әйтеп янчыкка салына. Бала янчыктагы уенчыкны капшап исемен әйтә, алып күрсәтә.
**8.Дидактик уен "Әйе-юк"**

Сүзнең дөрес үзләштерелүен тикшерү йөзеннән (аңлап яки аңламыйча әйтү) төрле вариантта сораулар бирелә: "Бу нәрсә?"- "Аю"...; "Бу аю?" - "Әйе, аю"...; "Бу куян?"-"Юк, песи"...
**<u>Югары балл (2,7-3)</u>** — сүз байлыгы җитәрлек, уенчык, әйберләрне үзлектән, аңлап дөрес күрсәтә, исемнәрен әйтә.
**<u>Уртача балл (2-2,6)</u>** - сүз байлыгы бар, кайбер сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.
**<u>Уртачадан түбән балл (1-1,9)</u>** - аңлый, русча җавап бирә.

2.**Ягымлы сүзләр куллану ("Исәнме", "Исәнмесез", "Сау бул" , "Сау булыгыз", "Рәхмәт", "Хәлләр ничек?")**

**1.Ситуатив күнегүләр.**
**а)"Куян аюга кунакка килә".** Ул ишектән кергәндә аюга нәрсә әйтә? (Ничек исәнләшә?) - "Исәнме аю".
**б)"Куян аюда кунакта булды".** Ишектән чыгып киткәндә куян аю белән ничек саубуллаша? (Нәрсә әйтә?) - "Сау бул, аю".
**в) "Акбайга ("Мияуга", "Курчакка", "Дустына") уенчык бүләк ит".**
**2. Уен ситуациясе "Кунак сыйлау".** Акбайда (Мияуда) кунакта.
Уен эчтәлеге: Тәрбияче Акбай (Мияу) ролендә. Ул баланы, ашамлык, җиләк-җимеш (алма, груша, банан һ.б.) муляжлары белән "сыйлый". Тәрбияче баланың "рәхмәт" әйтә белүен билгели.
**3.Уен ситуациясе "Дустыңны сыйла".** Балаларны парлаштырып бер-берсе белән исәнләшеп, хәлләрен сорап, сыйларга тәкъдим итү. Рәхмәт әйтә белүләрен билгеләү.

**<u>Югары балл (2,7-3)</u>** - бала ситуацияләрдә ягымлы сүзләрне урынлы куллана.

**<u>Уртача балл (2-2.6)</u>** - тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.

**<u>Уртачадан түбән (1-1,9)</u>** - аңлый, сорауга җавапны русча әйтә.

**3.Боерыкны аңлап үтәү һәм куллана белү (кил, утыр, ю, аша, эч, уйна)**

**1. Сүзле уен "Мин әйтәм - син эшлә" ("Командир").**
**2. Сүзле уен "Шаян уенчыклар"**. (Уен баланың боерыкларны аңлы рәвештә үтәвен тикшерү өчен бирелә. Уенның эчтәлеге: Тәрбияче уенчыкка боерык бирә, мәсәлән: Утыр! Ә уенчык "ашый" башлый. Бала боерыкны дөрес итеп үтәп күрсәтә).
**<u>Югары дәрәҗә (2,7-3)</u>** - бала боерыкны аңлап, дөрес үти.

**<u>Уртача дәрәҗә (2-2,6)</u>** - ялгыша.

**<u>Уртачадан түбән дәрәҗә (1-1,9)</u>** - татарча аңламый, боерыкларны үтәми.

**4.Тирә-юньдәге предметларның сыйфат билгеләрен, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану.**

**<u>1.Дидактик уен "Уенчык нинди?".</u>**
(Лексика: зур, кечкенә, чиста, пычрак, әйбәт, матур).
Уен эчтәлеге: Уенчыклар күрсәтелә. Тәрбиячене "Нинди?" соравына бала уенчыкны сыйфат билгесе белән атарга тиеш.
-Нинди курчак? - Зур (кечкенә, чиста, пычрак, әйбәт, матур) курчак.
**Эш дәфтәрендәге 11 нче биремне кулланып була.**
**<u>2.Дидактик уен"Тап, күрсәт һәм әйт</u>".**
(Лексика: чиста, пычрак).
Уен эчтәлеге: Комплекттагы күрсәтмә рәсемнәр кулланып үткәрелә. Тәрбияче әйткән рәсемне бала табып күрсәтә, әйтә. ("Чиста туп", "Пычрак аю"...).
**Эш дәфтәрендәге 13 нче биремне кулланып була.**
**<u>3.Дидактик уен "Курчакка бүләк".</u>**
(Лексика: зур, кечкенә).

Уен эчтәлеге: Тәрбияче зур курчакка - зур туп, кечкенә курчакка- кечкенә туп бүләк итәргә куша.“ Мә, зур туп ", “Мә, кечкенә туп".

**4.Дидактик уен "Дөрес сана".**

Санау күнекмәләрен билгеләү (1-5 кадәр). Тәрбияче уенчыклар, муляжлар санарга тәкъдим итә. Төркемдәге балаларны да санарга була. "Ничә малай?", "Ничә кыз?".

**5.Дидактик уен "Ничә?".**

Санау күнекмәләрен тикшерү өчен шулай ук, укыту методик комплектындагы күрсәтмә рәсемнәрне дә кулланып була.

- Ничә туп? - Биш туп.

**6. Сюжетлы-рольле уен: “Сыйлыйм”.**

(Лексика: тәмле)

- Оля, мә ипи, аша. Ипи тәмле(ме)?
- Әйе, ипи тәмле.

**Югары дәрәҗә (2,7-3)**- әйберләрнең сыйфат билгеләрен, күләмен исем белән кушып дөрес әйтә.

**Уртача дәрәҗә (2-2,6)** - 1-2 билгесен әйтә.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1-1,9)** - әйберләрнең билгеләрен, күләмен рус телендә әйтә.

